КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 гыйнвар г.Казань № 54

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында» 2022 ел, 12 апрель, 349 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алына торган җир кишәрлекләренең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең базар кыйммәтен бәяләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, җир кишәрлекләрен алышу шартнамәсен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә җибәрүне;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шартнамә төзүне;»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «килешү» сүзен «шартнамә» сүзенә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында» 2022 ел, 12 апрель, 350 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алына торган җир кишәрлекләренең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең базар кыйммәтен бәяләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, җир кишәрлекләрен алышу шартнамәсен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә җибәрүне;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шартнамә төзүне;»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «килешү» сүзен «шартнамә» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин